# КАРАР

**14 ноябрь, 2023 ел**

**№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Аман-Оштырма авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 14 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Аман-Оштырма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Аман-Оштырма авылы зиратын коймалау (материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Аман-Оштырма авылы зиратына кораллар һәм инвентарь сатып алу.
- Аман-Оштырма авылындагы юлларны кышкы һәм җәйге чорларда карап тоту (килешү буенча эш өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт өчен түләү),
- Аман-Оштырма авыл клубына җиһазлар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 65 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 36 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Аман-Оштырма авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Аман-Оштырма авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1200 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Аман-Оштырма авылы зиратында агачларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү, проект-смета докуменлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Аман-Оштырма авылы чишмәсен төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;

- Аман-Оштырма авылында урам-юл челтәрен карап тоту, килешү буенча эш өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре;

- янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларга комплект материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру һәм янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру буенча башка эш төрләре.

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Шәрипов

ОГРН 1021607753276
ИНН 1623001847